# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 1 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә территориаль планлаштыру, шәһәр төзелешен зоналаштыру, территорияне планлаштыру, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау өлкәсен җайга сала.

2. Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы белән билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

2 статья. **Шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы законнары**

Шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы законнары Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, башка федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларына нигезләнә һәм әлеге Законнан, Татарстан Республикасының башка законнарыннан һәм бүтән норматив хокукый актларыннан гыйбарәт.

3 статья. **Татарстан Республикасын һәм Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары**

1. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру документлары Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемаларыннан гыйбарәт. Әлеге схемаларны әзерләү Татарстан Республикасын территориаль

планлаштыруның бер яисә берничә документы составында гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү Татарстан Республикасының бөтен территориясенә яисә аның өлешләренә карата гамәлгә ашырылырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары муниципаль районнарны территориаль планлаштыру схемаларыннан һәм җирлекләрнең, шәһәр округларының генераль планнарыннан гыйбарәт.

4 статья. **Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасының составы**

1. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләрдән һәм тиешле карталардан (схемалардан) гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы составына керә торган Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру максатларын һәм бурычларын;

2) Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру гамәлләренең исемлеген һәм аларны үтәүнең эзлеклелеген.

3. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы составына керә торган карталарда (схемаларда) түбәндәгеләр чагылдырыла:

1) муниципаль берәмлекләрнең – шәһәр округларының, муниципаль районнарның, җирлекләрнең чикләре;

2) территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре;

3) табигать һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы һәм аларның нәтиҗәләренең йогынтысы янаган территорияләр чикләре;

4) урман фонды җирләренең чикләре, республика әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләре җирләренең чикләре, оборона һәм иминлек җирләренең чикләре;

5) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең чикләре һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр составындагы уңдырышлы авыл хуҗалыгы җирләренең чикләре, шулай ук мондый җирләрнең планлаштырылучы чикләре;

6) мәдәни мирас объектлары территорияләренең чикләре;

7) республика әһәмиятендәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен бирелгән, әлеге Законның 19 статьясы белән каралган яисә Татарстан Республикасы милкендәге капиталь төзелеш объектлары урнаштырылган җир кишәрлекләре чикләре;

8) әлеге Законның 19 статьясы белән каралган республика әһәмиятендәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырылучы зоналар чикләре.

4. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы барлык бүлекләр йә әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән аерым бүлекләр буенча әзерләнергә мөмкин.

5 статья. **Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү һәм аңа үзгәрешләр кертү тәртибе**

1. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү турындагы карар, әлеге схемага үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне әзерләү турындагы карар (әлеге статьяда алга таба – карар) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

2. Карарларда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын яисә мондый схемага үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне әзерләү эшләрен (әлеге статьяда алга таба – схеманы әзерләү яисә аңа үзгәрешләр кертү эше) финанслау сроклары, чыганагы, күләме һәм тәртибе;

2) схеманы әзерләү яисә аңа үзгәрешләр кертү эшләренең эзлеклелеге (этаплары);

3) чикләрендә территориаль планлаштыру схемасы әзерләнәчәк яисә схемага үзенә карата үзгәрешләр кертелә торган территория;

4) Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү эшләрен оештыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы;

5) территориаль планлаштыру схемасы составы.

3. Карар аны кабул иткәннән соң биш көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын, бүтән рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми серверында урнаштырыла.

4. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү эшләрен оештыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләүне, шулай ук Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы проектын федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда килештерүне тәэмин итә.

5. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләгәндә Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү эшләрен оештыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы проектын Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы проекты буенча тәкъдимнәр кертү өчен мәгариф, сәламәтлек саклау, дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура, спорт һәм туризм, гражданнар оборонасы, әйләнә-тирә мохитне саклау, мәдәният, хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, агросәнәгать комплексына идарә, архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш

материаллары сәнәгате, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынучы бүтән органнарына җибәрүне тәэмин итә.

6. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы проекты, аны расларга кимендә өч ай кала, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын, бүтән рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми серверында урнаштырыла. Әлеге Законның 4 статьясындагы 2 өлешендә каралган территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләр проекты һәм карта (схема) яисә әлеге Законның 4 статьясындагы 3 өлешендә каралган мәгълүмат чагылдырылган берничә карта (схема) проектлары бастырып чыгарылырга һәм урнаштырылырга тиеш.

7. Кызыксынучы затлар, Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы расланганчы, Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы проекты буенча үз тәкъдимнәрен әлеге схеманы әзерләү эшләрен оештыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына тапшырырга хокуклы.

8. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы, шул исәптән мондый схемага үзгәрешләр кертү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

9. Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасы аны раслаганнан соң Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын, бүтән рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми серверында урнаштырыла. Әлеге Законның 4 статьясындагы 2 өлешендә каралган территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләр һәм карта (схема) яисә әлеге Законның 4 статьясындагы 3 өлешендә каралган мәгълүмат чагылдырылган берничә карта (схема) бастырып чыгарылырга һәм урнаштырылырга тиеш.

10. Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең бүтән субъектларының дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, кызыксынучы физик һәм юридик затлар Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрен Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү эшләрен оештыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына тапшырырга хокуклы.

6 статья. **Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы составы**

1. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы муниципаль районны территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләрдән һәм тиешле карталардан (схемалардан) гыйбарәт.

2. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы составына керә торган муниципаль районны территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) муниципаль районны территориаль планлаштыру максатларын һәм бурычларын;

2) муниципаль районны территориаль планлаштыру гамәлләре исемлеген һәм аларны үтәүнең эзлеклелеген.

3. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы составына керә торган карталарда (схемаларда) түбәндәгеләр чагылдырыла:

1) муниципаль район составына керә торган җирлекләрнең гамәлдәге һәм планлаштырылучы чикләре;

2) территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре;

3) мәдәни мирас объектлары территорияләренең чикләре;

4) җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен бирелгән яисә муниципаль район мөлкәтендәге капиталь төзелеш объектлары урнаштырылган җир кишәрлекләре чикләре, шулай ук җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырылучы зоналар чикләре.

4. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы барлык бүлекләр йә әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән аерым бүлекләр буенча әзерләнергә мөмкин.

7 статья. **Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын әзерләү тәртибе, муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр әзерләү һәм кертү тәртибе**

1. Татарстан Республикасында муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын әзерләү турындагы карар, әлеге схемага үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне әзерләү турындагы карар (әлеге статьяда алга таба – карар) муниципаль районның уставы нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителә.

2. Карарларда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

1) муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын әзерләү яисә мондый схемага үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне әзерләү эшләрен (әлеге статьяда алга таба – схеманы әзерләү яисә аңа үзгәрешләр кертү эше) финанслау сроклары, чыганагы, күләме һәм тәртибе;

2) схеманы әзерләү яисә аңа үзгәрешләр кертү эшләренең эзлеклелеге (этаплары);

3) чикләрендә муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы әзерләнәчәк яисә схемага үзенә карата үзгәрешләр кертелә торган территория;

4) муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын әзерләү эшләрен оештыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле муниципаль район җирле үзидарә органы;

5) муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы составы.

3. Карар аны кабул иткәннән соң биш көн эчендә муниципаль хокукый актларны, бүтән рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш һәм Интернет челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында (муниципаль районның рәсми сайты булганда) урнаштырыла.

4. Муниципаль районның вәкаләтле—җирле үзидарә органы муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын әзерләүне оештыра.

5. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын әзерләгәндә муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасының проектын муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы проекты буенча тәкъдимнәр кертү өчен мәгариф, сәламәтлек саклау, дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура, спорт һәм туризм, гражданнар оборонасы, әйләнә-тирә мохитне саклау, мәдәният, хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, агросәнәгать комплексына идарә, архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынучы бүтән органнарына җибәрүне тәэмин итә.

6. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы проектын муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органы үз инициативасы буенча дәүләт экспертизасына җибәрергә мөмкин.

7. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасының проекты, аны расларга кимендә өч ай кала, муниципаль хокукый актларны, бүтән рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш һәм Интернет челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында (муниципаль районның рәсми сайты булганда) урнаштырыла. Әлеге Законның 6 статьясындагы 2 өлешендә каралган территориаль планлаштыру нигезләмәләренең проекты һәм карта (схема) яисә әлеге Законның 6 статьясындагы 3 өлешендә каралган мәгълүмат чагылдырылган берничә карта (схема) проектлары бастырып чыгарылырга һәм урнаштырылырга тиеш.

8. Кызыксынучы затлар, муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы расланганчы, муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы проекты буенча үз тәкъдимнәрен муниципаль районның вәкаләтле җирле үзидарә органына тапшырырга хокуклы.

9. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасының проекты аны раслаганчы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт тапшырылган федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә һичшиксез килештерелергә тиеш.

10. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы, аңа үзгәрешләр кертү муниципаль район җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы тарафыннан раслана.

11. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы расланган көненнән алып өч көн эчендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, муниципаль район составына керүче һәм территорияләренә карата муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы әзерләнгән җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына, муниципаль район белән уртак чиге булган муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарына һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

8 статья. **Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыру планын әзерләү**

1. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыру мондый схема расланган көннән алып өч ай эчендә муниципаль районның җирле администрациясе башлыгы тарафыннан раслана торган муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыру планы нигезендә башкарыла.

2. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыру планы түбәндәгеләрне исәпкә алып әзерләнә:

1) муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасы составына керә торган территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләрне;

2) Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарың, кызыксынучы физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен, аларны фактта гамәлгә ашыру мөмкинлеге очрагында.

3. Муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыру планы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру документациясен әзерләү срокларын, әлеге документация нигезендә мондый объектларны урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең чикләре билгеләнә яисә төгәлләштерелә;

2) проект документациясен әзерләү срокларын һәм җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын төзү срокларын;

3) муниципаль районны территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыруны финанс-икътисадый нигезләүне.

9 статья. **Җирлекләрнең, шәһәр округларының генераль планнары составы**

1. Җирлекләрнең, шәһәр округларының генераль планнары (алга таба – генераль планнар) җирлекләрне, шәһәр округларын территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләрдән һәм тиешле карталардан (схемалардан) гыйбарәт.

2. Генераль планнар составына керә торган җирлекләрне, шәһәр округларын территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләр түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) җирлекләрне, шәһәр округларын территориаль планлаштыру максатларын һәм бурычларын;

2) җирлекләрне, шәһәр округларын территориаль планлаштыру гамәлләренең исемлеген һәм аларны үтәүнең эзлеклелеген.

3. Генераль планнар составына керә торган карталарда (схемаларда) түбәндәгеләр чагылдырыла:

1) функциональ зоналарның чикләре, мондый зоналарның планлаштырыла торган үсеше параметрлары чагылдырылган килеш;

2) җирлекнең, шәһәр округының чикләре;

3) җирлек, шәһәр округы составына керә торган торак пунктларның чикләре;

4) территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре;

5) табигать һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы һәм аларның нәтиҗәләренең йогынтысы янаган территорияләр чикләре;

6) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең чикләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләренең чикләре, оборона һәм иминлек җирләренең чикләре, бүтән махсус билгеләнештәге җирләрнең чикләре, урман фонды җирләренең чикләре, су фонды җирләренең чикләре, федераль һәм республика әһәмиятендәге махсус сакланучы табигать территорияләре җирләренең чикләре;

7) сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә җирләренең гамәлдәге һәм планлаштырылучы чикләре;

8) мәдәни мирас объектлары территорияләренең чикләре;

9) федераль, республика яисә җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен бирелгән йә дәүләт яисә муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектлары урнаштырылган җир кишәрлекләренең чикләре, шулай ук федераль, республика яисә җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырылучы зоналар чикләре;

10) инженер һәм транспорт инфраструктуралары зоналары чикләре.

4. Генераль планнар составына керә торган карталар (схемалар) генераль планнарның проектларын әзерләү биреме белән, генераль планнарның гамәли көче кагыла торган территориянең мәйданын исәпкә алып, шулай ук халык санын (гамәлдәге һәм фаразлана торган) исәпкә алып билгеләнүче түбәндәге масштабларда әзерләнә:

1) 1:25000 - 1:10000 масштабы – халык саны биш йөз мең һәм аннан да күбрәк кеше булганда;

2) 1:10000 - 1:5000 масштабы – халык саны йөз мең кешедән алып биш йөз мең кешегә кадәр булганда;

3) 1:5000 масштабы – халык саны йөз мең кешедән ким булганда.

10 статья. **Җирлекләрнең, шәһәр округларының генераль планнарын әзерләү тәртибе, җирлекләрнең, шәһәр округларының генераль планнарына үзгәрешләр кертү тәртибе**

1. Генераль планны әзерләү турындагы карар, генераль планга үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне әзерләү турындагы карар (әлеге статьяда алга таба – карар) тиешенчә җирлекнең җирле администрациясе башлыгы, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан кабул ителә.

2. Карарларга түбәндәге белешмәләр керергә тиеш:

1) генераль планны әзерләү яисә аңа үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәрне әзерләү эшләрен (әлеге статьяда алга таба – генераль планны әзерләү яисә аңа үзгәрешләр кертү эше) финанслау сроклары, чыганагы, күләме һәм тәртибе;

2) генераль планны әзерләү яисә аңа үзгәрешләр кертү эшенең эзлеклелеге (этаплары);

3) чикләрендә генераль план әзерләнәчәк яисә генераль планга үзенә карата үзгәрешләр кертеләчәк территория;

4) җирлекнең, шәһәр округының генераль планны әзерләү эшләрен оештыру функциясен гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы;

5) генераль план составы.

3. Карар аны кабул иткәннән соң биш көн эчендә муниципаль хокукый актларны, бүтән рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш һәм Интернет челтәрендә җирлекнең рәсми сайтында (җирлекнең рәсми сайты булганда), шәһәр округының рәсми сайтында (шәһәр округының рәсми сайты булганда) урнаштырыла.

4. Җирлекнең, шәһәр округының вәкаләтле җирле үзидарә органы генераль планны әзерләүне оештыруны гамәлгә ашыра.

5. Генераль планны әзерләгәндә җирлекнең, шәһәр округының вәкаләтле җирле үзидарә органы генераль план проектын генераль план буенча тәкъдимнәр кертү өчен мәгариф, сәламәтлек саклау, дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура, спорт һәм туризм, гражданнар оборонасы, әйләнә-тирә мохитне саклау, мәдәният, хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, агросәнәгать комплексына идарә, архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынучы бүтән органнарына җибәрүне тәэмин итә.

6. Җирлекнең, шәһәр округының вәкаләтле җирле үзидарә органы үз инициативасы буенча генераль план проектын дәүләт экспертизасына җибәрергә мөмкин.

7. Генераль план проекты аны раслаганчы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт тапшырылган федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә һичшиксез килештерелергә тиеш.

8. Генераль план проекты, аны расларга кимендә өч ай кала, муниципаль хокукый актларны, бүтән рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен

билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш һәм Интернет челтәрендә җирлекнең рәсми сайтында (җирлекнең рәсми сайты булганда), шәһәр округының рәсми сайтында (шәһәр округының рәсми сайты булганда) урнаштырыла. Әлеге Законның 9 статьясындагы 2 өлешендә каралган территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләр проекты һәм карталар (схемалар) яисә әлеге Законның 9 статьясындагы 3 өлешендә каралган мәгълүмат чагылдырылган берничә карта (схема) проектлары бастырып чыгарылырга һәм урнаштырылырга тиеш.

9. Генераль план проекты Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясы нигезендә үткәрелүче гавами тыңлауларда һичшиксез каралырга тиеш.

10. Җирлекнең генераль планы, шәһәр округының генераль планы, аларга үзгәрешләр кертү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тиешенчә җирлек җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы, шәһәр округы җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы тарафыннан раслана.

11. Генераль план аны раслаган көннән алып өч көн эчендә (җирлекнең генераль планы расланган очракта) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына һәм чикләрендә җирлек урнашкан муниципаль район башлыгына җибәрелә.

12. Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, кызыксынучы физик һәм юридик затлар генераль планга үзгәрешләр кертү турындагы тәкъдимнәре белән җирлекнең җирле администрациясе башлыгына, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

13. Генераль планга торак төзелеше яисә рекреация билгеләнешендәге зоналарны ачыклау максатларында торак пунктларның чикләрен үзгәртү күз алдында тотыла торган үзгәрешләр кертү гавами тыңлаулар үткәрмичә генә гамәлгә ашырыла.

11 статья. **Җирлекнең генераль планын, шәһәр округының генераль планын гамәлгә ашыру планын әзерләү**

1. Җирлекнең генераль планын гамәлгә ашыру – җирлекнең җирле администрациясе башлыгы тарафыннан раслана торган җирлекнең генераль планын гамәлгә ашыру планы, шәһәр округының генераль планын гамәлгә ашыру шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан раслана торган шәһәр округының генераль планын гамәлгә ашыру планы нигезендә тиешле генераль план расланган көннән алып өч ай эчендә башкарыла.

2. Генераль планны гамәлгә ашыру планы түбәндәгеләрне исәпкә алып әзерләнә:

1) генераль план составындагы территориаль планлаштыру турындагы нигезләмәләрне;

2) Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының,

кызыксынучы физик һәм юридик затларның тәкъдимнәрен, аларны фактта гамәлгә ашыру мөмкинлеге очрагында.

3. Генераль планны гамәлгә ашыру планы түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең проектын әзерләү турындагы яисә җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы карарны;

2) җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен территорияне планлаштыру документациясен әзерләү срокларын, әлеге документация нигезендә мондый объектларны урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең чикләре билгеләнә яисә төгәлләштерелә;

3) проект документациясен әзерләү срокларын һәм җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын төзү срокларын;

4) генераль планны гамәлгә ашыруны финанс-икътисадый нигезләүне.

12 статья. **Генераль планнарның проектлары буенча гавами тыңлауларда катнашу өчен торак пункт территориясен өлешләргә бүлгәндә затларның иң чик саны**

Җирлекләрнең генераль планнарының, шәһәр округларының генераль планнарының проектлары буенча гавами тыңлаулар үткәргәндә кызыксынучы барлык затларга гавами тыңлауларда катнашу өчен бертигез мөмкинлекләр тәэмин итү максатларында, торак пункт территориясе өлешләргә бүленергә мөмкин. Территориянең мондый өлешендә яшәүче яисә теркәлгән гражданнарның саны түбәндәгечә булырга тиеш:

20 мең кешедән алып 100 мең кешегә кадәр – халкының саны 100 мең кешедән күбрәк булган торак пунктлар өчен;

15 мең кешедән алып 50 мең кешегә кадәр – халкының саны 50 меңнән алып 100 мең кешегә кадәр булган торак пунктлар өчен;

5 мең кешедән алып 10 мең кешегә кадәр – халкының саны 10 меңнән алып 50 мең кешегә кадәр булган торак пунктлар өчен;

3 мең кешедән алып 5 мең кешегә кадәр – халкының саны 10 мең кешедән азрак булган торак пунктлар өчен.

13 статья. **Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары составы**

1. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларына территорияләрнең типлары (күләмнәре, территориаль тыгызлыгы һәм халкының демографик составы) буенча дифференциацияләнгән минималь (исәп-хисап) күрсәткечләре түбәндәгеләр өчен керә:

1) урнашуларына бәйле рәвештә төрле билгеләнештәге территорияләрдән файдалануның интенсивлыгын, шулай ук, түбәндәге исәп-хисап күрсәткечләрен дә кертеп, мондый территорияләр үсешенең куелган бурычларына эзлекле рәвештә ирешү этапларын билгеләү:

а) торак территориаль зоналардагы халыкның территориянең бер гектарына кешеләр санында белдерелгән тыгызлыгын һәм (яисә) территория үсешенең төрле этапларында торак белән тәэмин итүнең төрле күрсәткечләрендә территориянең бер гектарына гомуми торак мәйданының квадрат метрлардагы торак фонды тыгызлыгын;

б) бүтән билгеләнештәге территорияләрдән файдалануның төзелеш алып бару процентларында белдерелгән интенсивлыгын;

2) тәкъдим ителүче исәп-хисап күрсәткечләрен дә кертеп, төрле билгеләнештәге территорияләргә булган ихтыяҗны билгеләү:

а) капиталь төзелешнең төрле объектларын урнаштыру өчен территорияләрне;

б) планлаштырылучы структураның төрле элементларына (кварталларга, микрорайоннарга, районнарга) һәм төзелеш алып баруның типларына карата гомуми файдаланудагы территорияләрне, шул исәптән паркларның, бакчаларның, скверларның, бульварларның территорияләрен;

в) автомобильләштерүнең фаразланучы дәрәҗәсен (даими яшәүче һәм килгән халыкның бер мең кешесенә туры килә торган автомобильләр саныннан) исәпкә алып, юллар һәм урамнар челтәрен үстерү өчен территорияләрне;

г) инженер-техник тәэмин итү объектларын үстерү өчен территорияләрне;

3) дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗлар өчен кирәкле капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең күләмнәрен билгеләү, түбәндәгеләрне урнаштыру өчен җир кишәрлекләре күләмнәренең техник регламентларны исәпкә алып билгеләнүче тәкъдим ителә торган исәп-хисап күрсәткечләрен дә кертеп:

а) социаль хезмәт күрсәтү объектларын;

б) коммуналь хезмәт күрсәтү объектларын;

в) юл һәм инженер-техник инфраструктураның линия объектларын; индивидуаль һәм бүтән төрле транспортны саклау объектларын; бүтән объектларны;

4) төрле типлардагы тиешле объектларга кадәрге һәм төрле планлаштыру шартларына карата ераклыкларны билгеләү юлы белән социаль-хезмәт күрсәтү объектларының һәркем кереп йөри алырлык булуын (җәяү, транспорт белән) тәэмин итү;

5) территорияне планлаштыру проектларын һәм территорияне ызанлау проектларын әзерләгәндә түбәндәгеләрне билгеләү:

а) күпфатирлы йортларны да кертеп, гамәлдәге биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан файдалану өчен бирелә торган җир кишәрлекләренең күләмнәрен;

б) территориянең планлаштырылучы структурасының төрле элементларына карата проектланучы урамнар, үтеп йөрү юллары, аерылып китү мәйданнары; төрле типлардагы һәм төрле планлаштыру шартларындагы биналар, төзелмәләр һәм корылмалар арасындагы ераклыкларны.

2. Шәһәр төзелешен проектлауның түбәндәге төрләрдәге республика нормативлары булырга мөмкин:

1) торак зонасының шәһәр төзелешен проектлау нормативлары;

2) иҗтимагый-эшлекле зонаның шәһәр төзелешен проектлау нормативлары;

3) җитештерү зонасының шәһәр төзелешен проектлау нормативлары;

4) инженер һәм транспорт инфраструктуралары зоналарының шәһәр төзелешен проектлау нормативлары;

5) авыл хуҗалыгы файдалануындагы зоналарның шәһәр төзелешен проектлау нормативлары;

6) рекреация билгеләнешендәге зоналарның шәһәр төзелешен проектлау нормативлары;

7) махсус саклanучы территорияләр зоналарының шәһәр төзелешен проектлау нормативлары;

8) махсус билгеләнештәге зоналарның шәһәр төзелешен проектлау нормативлары.

3. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын әзерләгәндә аларның эчтәлеге Татарстан Республикасы чикләрендәге җирлекләрнең, шәһәр округларының үзенчәлекләрен, шулай ук Татарстан Республикасының социаль-икътисадый шартларын исәпкә алып төгәлләштерелергә мөмкин.

14 статья. **Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын әзерләү һәм раслау тәртибе**

1. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын әзерләү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителә.

2. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын әзерләү турындагы карар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми серверында урнаштырыла.

3. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы чикләрендә җирлекләрнең, шәһәр округларының үзенчәлекләрен исәпкә алып, шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын раслау максатларында аларны эшләүне һәм килештерүне тәэмин итә. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын эшләү дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китереп торуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Билгеләнгән тәртиптә әзерләнгән шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары проекты килештерү өчен шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан түбәндәгеләргә җибәрелә:

1) Татарстан Республикасы муниципаль районнарының, шәһәр округларының, җирлекләренең башлыкларына;

2) Татарстан Республикасын икътисадый үстерүгә идарә буенча дәүләт сәясәтен эшләү өлкәсендә, мәдәният, әйләнә-тирә мохитне саклау, гражданнар оборонасы, дәүләт яшьләр сәясәте, физик культура, спорт һәм туризм, хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау, мәгариф, агросәнәгать

комплексына идарә, дәүләт төзелеше күзәтчелеге, территориаль планлаштыру документларының проектларына, проект документациясенә һәм инженер эзләнүләренең нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасы өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына, шулай ук Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынучы бүтән органнарына.

5. Әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән органнар үзләренә шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары проекты җибәрелгән көннән алып утыз көн эчендә шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары проектын килештерү турындагы йә, сәбәпләрен нигезләп, аны килештерүдән баш тарту турындагы карарны шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына тапшырырга тиеш.

6. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына әлеге статьяның 5 өлеше белән билгеләнгән срокта әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән органнарның бәяләмәләре килмәгән очракта, шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары проекты кисәтүләрсез генә мондый органнар белән килештерелгән дип санала.

7. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән срок тәмамланган көннән алып бер ай эчендә шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларының килештерелгән проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

8. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының норматив хокукый актларын, бүтән рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылырга тиеш һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми серверында урнаштырыла.

9. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын раслау турындагы карар кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы аны шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системаларында урнаштыру өчен Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына тапшыруны тәэмин итә.

10. Шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларына үзгәрешләр кертү шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативларын әзерләү һәм раслау өчен әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

15 статья. **Җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең проектын әзерләү комиссиясе составы**

1. Җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең проектын әзерләү комиссиясе (алга таба – комиссия) даими эшләүче, шул исәптән җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең проектын әзерләү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү, җирләрдән

файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренең проекты буенча билгеләнгән тәртиптә гавами тыңлаулар үткәрү өчен, шулай ук капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча оештырылучы коллегиаль орган була.

2. Комиссия составы Татарстан Республикасында җирлекнең, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан раслана. Бу чакта комиссия составына Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынучы органнарының вәкилләре дә кертелергә мөмкин.

3. Комиссия үз әгъзаларының гомуми санының биштән кимрәк булмаган һәм егерме биш кешедән артыграк булмаган так саныннан торырга тиеш.

16 статья. **Җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе эшчәнлеге тәртибе**

1. Комиссия эшчәнлеге тәртибе Татарстан Республикасында җирлекнең, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы тарафыннан раслана.

2. Комиссия үз эшчәнлеген утырышлар рәвешендә гамәлгә ашыра. Комиссия утырышлары кворум булганда кирәк саен үткәрелә. Комиссия утырышларын аның рәисе яисә рәисенең урынбасары алып бара. Аларның икесе дә булмаганда, утырышны комиссия рәисе вәкаләт тапшырган комиссия әгъзасы алып бара.

3. Комиссия карарлары утырыштагы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

4. Комиссиянең һәр утырышының йомгаклары комиссия рәисе һәм комиссия әгъзалары имза салган, утырыш темасына бәйле материалларның күчермәләре кушып бирелә торган беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

5. Комиссиянең барлык утырышларының беркетмәләреннән, комиссия эшчәнлегенә бәйле бүтән материаллардан торган үз архивы була.

17 статья. **Әзерләве Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру документлары, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары нигезендә гамәлгә ашырыла торган территорияне планлаштыру проектларының составы һәм эчтәлеге**

1. Әзерләве Татарстан Республикасын территориаль планлаштыру документлары, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрне территориаль планлаштыру документлары нигезендә гамәлгә ашырыла торган территорияне планлаштыру проекты (алга таба – территорияне планлаштыру проекты) расланырга тиешле төп өлештән һәм аны нигезләү материалларыннан гыйбарәт.

2. Территорияне планлаштыру проектының расланырга тиешле төп өлеше түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) территорияне планлаштыру сызымын яисә сызымнарын, аларда түбәндәгеләр чагылдырыла:

а) кызыл сызыклар;

б) юлларны, урамнарны, үтеп йөрү юлларын, элемтә линияләрен, инженер һәм транспорт инфраструктуралары объектларын белдерүче сызыклар;

в) социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнештәге объектларны, капиталь төзелешнең бүтән объектларын урнаштыру планлаштырылучы зоналарның чикләре;

2) республика һәм җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектларын урнаштыру турындагы, шулай ук территорияне планлаштырылучы үстерү характеристикалары турындагы, шул исәптән территориядә төзелеш алып баруның тыгызлыгы һәм параметрлары, социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм территорияне үстерү өчен кирәкле инженер-техник тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турындагы нигезләмәләрне.

3. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү материалларына график формадагы материаллар һәм аңлатма керә.

4. Территорияне планлаштыру проектын нигезләүнең график формадагы материаллары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) планлаштырылучы структура элементының урнашу схемасын;

2) территорияне планлаштыру проектын әзерләү чорында территориядән файдалану схемасын;

3) урамнар-юллар челтәрен оештыру схемасын һәм тиешле территориядә транспорт хәрәкәте схемасын;

4) мәдәни мирас объектлары территорияләренең чикләре схемасын;

5) территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналарның чикләре схемасын;

6) территорияне вертикаль планлаштыру һәм инженерлык әзерләве схемасын;

7) территорияне планлаштыру турындагы нигезләмәләрне нигезләү өчен график формадагы бүтән материалларны.

5. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән аңлатмага түбәндәгеләргә кагылышлы нигезләмәләрне тасвирлау һәм нигезләү керә:

1) социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм территорияне үстерү өчен кирәкле инженер-техник тәэмин итү системаларының планлаштырылучы төзелеше параметрларын билгеләүгә;

2) территорияне табигать һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклауга, гражданнар оборонасы һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү гамәлләрен үткәрүгә;

3) территорияне планлаштыруның бүтән мәсьәләләренә.

6. Территорияне планлаштыру проектының масштабы үзенә карата планлаштыру гамәлгә ашырыла торган территория күләмнәренә һәм шәһәр төзелешен проектлауның технологик үзенчәлекләренә бәйле рәвештә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

18 статья. **Әзерләве Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары карарлары нигезендә гамәлгә ашырыла торган территорияне планлаштыру документациясен әзерләү тәртибе**

1. Территорияне планлаштыру документациясен әзерләү Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Территорияне планлаштыру документациясен әзерләү турындагы карар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан аның үз инициативасы буенча йә дәүләт хакимияте органнарының, физик яисә юридик затларның территорияне планлаштыру хакындагы документацияне әзерләү турындагы тәкъдимнәре нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясындагы $8^1$ өлешендә күрсәтелгән затларның территорияне планлаштыру документациясен әзерләү турында карарлар кабул итү хакындагы гаризалары нигезендә кабул итеп алына.

3. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә кабул ителгән карар турында территорияләренә карата мондый карар кабул ителгән җирлек башлыгына, шәһәр округы башлыгына хәбәрнамә җибәрә.

4. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документацияне әлеге статьяның 5 өлешендә каралган таләпләргә туры килү-килмәү предметына килештерү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең кызыксынучы органнарына җибәрә. Территорияне планлаштыру документациясен килештерү срогы аны җибәргән вакыттан алып күп дигәндә утыз көн тәшкил итә.

5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән срок тәмамланган көннән алып утыз көн эчендә территорияне планлаштыру буенча әзерләнгән документациянең түбәндәгеләргә туры килү-килмәвен тикшерә:

1) территориаль планлаштыру схемасына;

2) җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә;

3) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрнең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары территорияләренең чикләрен, яңа ачыкланган мәдәни мирас объектларының территорияләре чикләрен, территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләрен исәпкә алып, техник регламентлар, шәһәр төзелеше регламентлары таләпләренә.

6. Тикшерү нәтиҗәләре буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы җиде көн эчендә мондый документацияне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына раслауга җибәрү турында яисә аны кире кагу турында һәм аны эшләп бетерүгә җибәрү турында карар кабул итә.

7. Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан тапшырылган территорияне планлаштыру документациясе әлеге документация кергән көннән соң ундүрт көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

8. Территорияне планлаштыру документациясе расланган көненнән соң җиде көн эчендә территорияләренә карата мондый документация әзерләнгән җирлек башлыгына, шәһәр округы башлыгына шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан җибәрелә.

9. Җирле администрация башлыгы әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән территорияне планлаштыру документациясен муниципаль хокукый актларны, бүтән рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны һәм мондый документация турындагы мәгълүмат Интернет челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында (муниципаль берәмлекнең рәсми сайты булганда) урнаштыруны тәэмин итә.

19 статья. **Республика әһәмиятендәге капиталь төзелеш объектлары**

Республика әһәмиятендәге капиталь төзелеш объектларына түбәндәгеләр керә:

1) республика әһәмиятендәге энергетика системалары объектлары;

2) республика әһәмиятендәге транспорт, юллар, мәгълүматлаштыру һәм элемтә объектлары;

3) табигый монополияләр субъектларының эшчәнлеген тәэмин итүче республика әһәмиятендәге линия объектлары;

4) республика әһәмиятендәге махсус сакланылучы табигать территорияләре режимын тәэмин итүче объектлар;

5) республика әһәмиятендәге инженерлык яклавы объектлары һәм гидротехник корылмалар;

6) Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге капиталь төзелеш объектлары, шулай ук Татарстан Республикасы милкендәге, шул исәптән Татарстан Республикасының дәүләт ихтыяҗлары өчен резервланган, җир кишәрлекләрендә урнаштыруга планлаштырылучы объектлар;

7) Татарстан Республикасын икътисадый һәм социаль үстерү программалары белән билгеләнгән Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең өстенлекле юнәлешләре нигезендә урнаштырылган яисә төзелергә планлаштырылучы капиталь төзелеш объектлары.

20 статья. **Шәһәр төзелеше регламентларының гамәли көче кагылмый торган яисә үзләре өчен шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җир кишәрлекләрендә төзелешкә рөхсәтләр бирү тәртибе**

1. Төзелеш алып баручылар, шәһәр төзелеше регламентларының гамәли көче кагылмый торган яисә үзләре өчен шәһәр төзелеше регламентлары билгеләнми торган җир кишәрлекләрендә капиталь төзелеш объектларын төзү,

реконструкцияләү, капиталь ремонтлау максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына, җирле үзидарә органына төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза җибәрәләр. Әлеге гаризага Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7 өлешендә (5 пунктында күрсәтелгән документлардан тыш) һәм 9 өлешендә каралган документлар кушып бирелә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән органнар төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гаризаны алган көннән алып ун көн эчендә:

1) гаризага кушып бирелә торган документларның булу-булмавын тикшерәләр;

2) проект документациясенең җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы таләпләренә, кызыл сызыкларга туры килү-килмәвен тикшерәләр;

3) төзелешкә рөхсәт бирәләр яисә, мондый баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, рөхсәт бирүдән баш тарталар.

3. Төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы төзелеш алып баручының гаризасы буенча төзелешнең, реконструкциянең аерым этапларына рөхсәт бирергә мөмкин.

4. Төзелешкә рөхсәтләр бирүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7 өлешендә (5 пунктында күрсәтелгән документлардан тыш) һәм 9 өлешендә каралган документлар булмаганда яисә тәкъдим ителгән документлар җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы таләпләренә туры килмәгәндә төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарта.

5. Төзелеш алып баручы төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тартуга карата суд тәртибендә шикаять бирә ала.

6. Капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау барышында төзелеш алып баручы проект документациясеннән тайпылуы, лицензиянең гамәли срогы тәмамлану һәм төзелешкә рөхсәт бирелгән бүтән шартларның үзгәрүе турында төзелешкә рөхсәт биргән органга хәбәр итәргә тиеш.

21 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 25 декабре
№ 98-ТРЗ